**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы 12 өлеше нигезендә **карар бирәм:**

1. 2020 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 3 маендагы ПУ-347 номерлы, 2018 елның 4 августындагы ПУ-550 номерлы һәм 2019 елның 13 августындагы ПУ-466 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи окладлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-242 номерлы Указы нигезендә билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең үзләре биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына туры килгән айлык окладлары күләмен (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары) арттырырга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләгәндә әлеге Указның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары территориаль органнарының кече төркем вазыйфалары «тәэмин итүче белгеч» категориясе 3 разрядлы белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,03 тапкырга индексацияләргә һәм ул 11 498 сум тәшкил итәчәк.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованияләре күләмендә финанслауны башкарырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 15 август
№ ПУ-498